**АЙЛЫК БАЛАЛАР ГӘҖИТЕ. №3 ЯНВАРЬ 2025**

https://vk.com/dou_6sandugach_arsk

https://edu.tatar.ru/arsk/page3737575.ht

# Чишмә башы

**Татарстан Республикасы Арча муниципальрайоны “Арча шәһәренең гомуми үсеш бирү төрендәге 6 нчы номерлы “Сандугач” балалар бакчасы” муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесы**

## Безнен яңалыклар:

*“Арча шәһәре, аның истәлекле урыннары”*

*“Кунак көтәбез әле”*

*“Татар халык уеннары”*



**ГАЗИЗ ТУГАН ТЕЛЕБЕЗ- ТАТАР ТЕЛЕН КАДЕРЛИК, ЯКЛЫЙК, САКЛЫЙК!**

## *“Кунак көтәбез әле”*

***Балаларны кунакчыл булырга, хөрмәт күрсәтергә өйрәтү; татар халкының милли ризыклары белән таныштыру; халкыбызның гореф-гадәтләренә, үткәненә ихтирам, хөрмәт һәм кызыксыну уяту; туган телебезгә мәхәббәт хисе тәрбияләү максатыннан кечкенэ курчагыбыз Лэйлэ кечкенэлэр торкемендэге сабыйларны өстэл янына жыйды. Халкыбызның күркәм гадәтләренең берсе – кунакчыллык турында сөйләште, милли ризыкларыбыз белэн таныштырды. Әби-бабайларыбыз элек-электән бик кунакчыл булганнар, кунакка ачык йөз, сый-хөрмәт күрсәткәннәр. Кунакны сыйлау-узе бер хормэт ул. Татар халкы элек-электән кунакка килгәндә күчтәнәч белән килгән. Бу шулай ук бик күркәм гадәт. Сонынннан Лэйлэ дэ балаларны узе алып килгэн чэк-чэк белэн сыйлады. Безнен балалар бакчасында халкыбызның гореф-гадәтләренә, үткәненә ихтирам, хөрмәт һәм кызыксыну уяту; татар халык уеннары, иҗаты аша туган телебезгә мәхәббәт хисе тәрбияләү чагылдырылган торле чаралар хэрдаим уздырыла.***

***Татар теленә өйрәтү тәрбиячесе: Шакирова Л. А.***







## *“Татар халык уеннары”*

***Татар халык уеннары беркайчан да үзләренең актуальлеген югалтмаслар , мөгаен. Борын-борын заманнарда безнең бабаларыбыз да балачакта матур-матур уеннар уйнап үскәннәр. Уеннар һәрвакыт халыкның үткән заманнардагы көнкүрешен, тормышын чагылдыралар. Әмма уеннар тормыш вакыйгаларын гына кабатламый, алай гына булса, уенның бер кызыгы да булмас иде. Алар да, әкиятләр, җырлар кебек үк, буыннардан — буынга күчә-күчә шомарганнар, аларга яңа кызыклы вакыйгалар, сүзләр, хәрәкәтләр өстәлгән. Шулай итеп уен мавыктыргыч, кызыклы булып киткән. Бу уеннарны бүгенгесе көндә дә балалар бакчаларында бик яратып уйныйлар. Шундый уеннарнын берсе - "Түбәтәй" уены. "Бал кортлары" төркемендә тәрбияләнүче балаларыбыз әлеге уен белән таныштылар. Балалар түгәрәкләнеп басалар. Җыр җырлый-җырлый, түбәтәйне бар-берсенә бирәләр. Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә. Балаларга "Түбәтәй" уены бик ошады.***

***Кечкенәләр төркеме тәрбиячесе: Бакирова Д. М.***

## ***<u>Безнең уңышларыбыз!</u>***

***19 декабрь көнне Арча шәһәренең 1 нче номерлы балалар бакчасында “Ел тәрбиячесе- 2025” Республика күләм конкурсының район туры үтте. Бу конкурста безнең балалар бакчасыннан Шакирова Зилә Мидехат кызы катнашып 2 урынга лаек булды! Аңа алдагы этапта уңышлар, якты җиңүләр телибез!***



## *“Арча шәһәре, һәм аның истәлекле урыннары”*

***Без бүген "Йолдызчык" икенче кечкенәләр төркемендә татар теле шөгылендә Арча шәһәре,аның истәлекле урыннары турында сөйләштек. Балалар шәһәр үзәгендә урнашкан Социалистик Хезмәт Геройлары аллеясы, халык язучылары аллеясы, Сызгановлар йорты, “Дан” мемориалы, репрессия корбаннары хөрмәтенә куелган һәйкәлләрнең рәсемнәре белән таныштылар. Алар бик күп кызыклы мәгълүмат ишеттеләр һәм истәлекле урыннар турында тарихи вакыйгаларны аеруча кызыксыну белән тыңладылар. Арча -матур ,зур,данлыклы шәһәр. Шәһәребездә биек йортлар күп. Шөгылебез ахырында йомгак ясалды: шәһәребез матур булсын өчен- агачлар,чәчәкләр утыртырга, урамнарны чиста тотарга, чүп ташламаска, әйберләрне ватмаска кирәклегенә басым ясадык. Балаларыбызда үзләренең матур, зур, чиста шәһәрдә яшәүләре белән горурлану хисе уянды, шатлык хисе туды. Яраткан Арча шәһәребез, яшә һәм чәчәк ат!***

***Икенче кечкенәләр төркеме тәрбиячесе: Шарифуллина Г. Ф.***

***Елның иң гаҗәп, иң гүзәл, иң матур фасылы- Кыш. Рәссамнар аны үз картиналарында данлыйлар. Чөнки табигать кыш көне үзенчәлекле, һәм үзенең чисталыгы һәм сафлыгы белән балкып тора. Безнең балалар бакчасында “Объективта Кыш” фотоконкурсы игълан ителгән иде. Балалар һәм әти- әниләр әлеге конкурста бик теләп катнаштылар. Бу күргәзмәдә сез Арчабызның иң матур кышкы табигатен күрә аласыз!***



